ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАЛОЛЫЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КЕЧЕ ЛЫЗИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
20.03.2023 г.

КАРАР
№ 20

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге территориясендә файдаланылган терекөмөшле лампаларны туплану урынын (урыннарын) булдыру һәм кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 24.06.1998 № 89-ФЗ, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 10.01.2002 №7-ФЗ, «Энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 23.11.2009 № 261-ФЗ Федераль законнарга ярашлы рәвештә, 06.10.2003 № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», Татарстан Республикасының 28.07.2004 ТРЗ№45 «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында», Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28.12.2020 № 2314 «Тиешсез җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм аларны урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырту җайланмалары, электр лампалары ягыннан җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында Кагидә раслау турында»карары нигезендә, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге территориясендә файдаланган терекөмошле лампалар туплану урынын (урыннарын) түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Балтач муниципаль районы, Кече Лызи авылы, Центральная урамы, 2 йорт.

2. Милекчеләре, яллаучылары, кулланучылары булган күпфатирлы йортларда тиешсез җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган, кулланучылар файдаланган терекөмөшле лампаларны туплану урыннары яктырткыч җайланмалар, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28.12.2020 № 2314 карары белән расланган кагыйдәләренең 4 пункты нигезендә билгеләнә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән терегөмөшле лампаларның

туплану урыннары, әгәр күпфатирлы йортларда терекөмешле лампаларның туплану урыннарын оештыру мөмкин булмаса, бу йортларда кулланучылар файдаланган терекөмешле лампаларны туплану урынны да булып тора.

4. Кулланучыларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампалар тупланган урынның (урыннарның) урнашуы турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге җирле үзидарә органнары биналарында урнаштыру юлы белән хәбәр итәргә.

5. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл жирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге территориясендә терегөмешле лампаларны беренчел җыю һәм вакытлыча урнаштыру урынын билгеләү турында» 17.12.2021 №24 карары үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталы" интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми (baltasi.tatarstan.ru) һәм Кече Лызи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы А.С.Исмагилов